Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Баграж-Никольский авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАРЫ

18 май 2022 ел № 6

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Баграж-Никольский авыл җирлеге башкарма комитетының 2012 елның 18 апрелендә кабул ителгән 3 номерлы «Әлмәт муниципаль районы Баграж-Никольский авыл җирлеге башкарма комитетында муниципаль хезмәте вазыйфасын биләүче затларның һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны Әлмәт муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру һәм әлеге мәгълүматларны бастырып чыгару өчен массакүләм мәгълүмат чараларына бирү тәртибен раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

«Санлы финанс активлары, санлы валюта һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында «Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2020 елның 10 декабрендәге 778 номерлы РФ Президенты Указы нигезендә, Әлмәт шәһәре прокуратурасының 19 апрелендә 2022 елның 02-08-02/159-2022 номерлы протестын карап

Баграж-Никольский авыл җирлеге башкарма комитеты
КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Баграж-Никольский авыл җирлеге башкарма комитетының 2012 елның 18 апрелендә кабул ителгән 3 номерлы "Әлмәт муниципаль районы Баграж-Никольский авыл җирлеге башкарма комитетында муниципаль хезмәте вазыйфасын биләүче затларның һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны Әлмәт муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру һәм әлеге мәгълүматларны бастырып чыгару өчен массакүләм мәгълүмат чараларына бирү тәртибен раслау турында» карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

карарга 1 нче кушымтаның 2 пунктындагы г) пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә;

«г) җир кишәрлеген, күчемсез мөлкәтнең башка объектын, транспорт чарасын, кыйммәтле кәгазьләрне (оешмаларның устав (җыелма) капиталларында катнашу өлеше, пайлар, цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта сатып алу буенча алыш-бирешләрнең гомуми суммасы хезмәткәрнең (хезмәткәрнең) һәм аның хатынының (иренең) гомуми кеременнән артып киткән очракта, акча алу чыганаклары турында белешмәләр.»;

карарга 2 нче кушымта формасында «акцияләр» сүзен төшереп калдырырга;

карар исемендә һәм алга таба да карарның һәм 1 нче кушымтаның барлык тексты буенча тиешле килештә «рәсми сайт» сүзләрен «Интернет «мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Әлмәт муниципаль районы сайтында» сүзләре белән алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Баграж-Никольский авылы, Дальняя Ивановка авылы, Яшьләр урамы, 26 нчы йорт; Баграж-Никольский авылы, Үзәк урам, 31б йорты территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU), «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Баграж-Никольский авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе Н.М. Новиков